| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 май 2020 ел. Буа шәһәре 3-53 номерлы

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
муниципаль берәмлекләрнең чикләрен үзгәртү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Наратбаш, Татар Буасы, Ырыңгы авыл җирлекләре чикләренә керүче җир кишәрлекләрен кушымта итеп бирелә торган картам-схемалар нигезендә «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенә кертү юлы белән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре», «Татар Буасы авыл җирлеге», «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» һәм «Ырыңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү инициативасы белән чыгарга.

2. Буа муниципаль районының «Буа шәһәре», «Татар Буасы авыл җирлеге», «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» һәм «Ырыңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына «Буа шәһәре», «Татар Буасы авыл җирлеге», «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» һәм «Ырыңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре чикләрен тәкъдим ителә торган үзгәртү буенча фикер белдерергә тәкъдим итәргә.

3. Буа муниципаль районы Советының 2019 елның 30 октябрендә кабул ителгән «Буа муниципаль районы җирлекләре чикләре турында»гы 1-46 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.


4. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча http://buinsk.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Буа муниципаль районы
башлыгы урынбасары,
Буа муниципаль районы
Советы рәисе урынбасары И.Ф. Еремеев

Муниципаль берәмлекләр чикләренең
үзгәрешләрен исәпкә алган
Карта-схема

«Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Советының
«____» ___________2020елның
______ номерлы карарына 1 кушымта




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чикләре

- Буа муниципаль районы чикләре

- муниципаль берәмлекләр чикләре

-А-Б - Түбән Наратбаш авыл җирлеге һәм "Буа шәһәре" муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге

- В-Г - Ырыңгы авыл җирлеге һәм "Буа шәһәре" муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- Г-Д - Татар Буасы авыл җирлеге һәм "Буа шәһәре" муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге

- Җирлекләрнең административ үзәкләре

- торак пунктлар


- Буа муниципаль районының "Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелгән Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге территориясе

- Буа муниципаль районының "Бау шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелгән Буа муниципаль районының Ырыңгы авыл җирлеге территориясе

- Буа муниципаль районының "Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелгән Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлеге

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының
«____» ___________2020елның ______ номерлы карарына 2 кушымта

## Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм «Татар Буасы авыл җирлеге», «Ырыңгы авыл җирлеге», « Түбән Наратбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре арасында проект чиге




*Масштабы 1: 45000*

*Шартлы билгеләр:*

*– муниципаль берәмлекләрнең гамәлдәге чикләре*

*– муниципаль берәмлекләрнең проект чикләре*

*- Буа муниципаль районының "Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге составына керүче "Татар Буасы" муниципаль берәмлеге территориясе (250,86 Га)*

*- Буа муниципаль районының "Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге составына керүче "Түбән Наратбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе (50,95 Га)*

*- Буа муниципаль районының "Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге составына керүче "Ырыңгы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе (285,94 Га)*

*Килештерелгән:*

| | |
|---|---|
| *Буа муниципаль районы "Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы* | *С.А. Зайцева* |
| *Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлеге башлыгы* | *Р.Ф. Юсупов* |
| *Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгы* | *И.И. Галиуллин* |
| *Буа муниципаль районы Ырыңгы авыл җирлеге башлыгы* | *Р.И. Гордеев* |